КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 ноябрь г.Казань № б-2672

Татарстан Республикасы Рәисенең «Каюм Насыйри тууының 200 еллыгын бәйрәм итү турында» 2023 елның 22 мартындагы 177 номерлы Указын үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2025 елда Татарстан Республикасында Каюм Насыйри тууының 200 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча төп чаралар планын (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Планны гамәлгә ашыруда катнашуны тәкъдим итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Планны мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 27 ноябрь, б-2672 нче
боерыгы белән расланды

2025 елда Татарстан Республикасында Каюм Насыйри тууының
200 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча төп чаралар планы

| Т/с | Чара | Үткәрү срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | **Төп юбилей чаралары һәм тантаналы чаралар** | | |
| 1. | Ремонт-реставрация эшләреннән соң Каюм Насыйри исемендәге архитектура-этнография комплексын ачу тантанасы (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авылы) | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| 2. | Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышланган юбилей кичәсен үткәрү | 2025 елның феврале | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), «Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| 3. | Россия Федерациясе Үзәк банкына «Россиянең күренекле шәхесләре» сериясендә «Галим-мәгъ-рифәтче Каюм Насыйри, тууының 200 еллыгына» | 2025 ел | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | дигән истәлек тәңкә чыгару турында тәкъдим кертү | | |
| 4. | Татарстан Республикасы китапханәләрендә Каюм Насыйри тууының 200 еллыгына багышланган чаралар үткәрү | 2025 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль китапханәләре (килешү буенча) |
| 5. | Татарстан Республикасының мәгариф оешма-ларында Каюм Насыйри тууының 200 еллыгына багышланган чаралар үткәрү | 2025 ел | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы мәгариф оешмалары (килешү буенча) |
| 6. | «Күпкырлы Россия» бөтенроссия маршруты кысаларында «Энциклопедист галим эзләре буенча» мәдәни-туристик маршрутны (Казан шәһәре – Кече Шырдан авылы) гамәлгә ашыру | 2025 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| | **Күргәзмә проектлары** | | |
| 7. | Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышланган күргәзмәләр үткәрү | 2025 елның 14 феврале – 20 мае | Татарстан Республикасы Мәдәният министр-лыгы, «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе (килешү буенча) |
| 8. | «Каюм Насыйри – этнограф», «Каюм Насыйри – татар мәгърифәтчесе», «Бөек галим Каюм Насыйри», «Каюм Насыйри: кичә, бүген, иртәгә» | 2025 ел | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), «Зеленодольск муниципаль |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | күргәзмә проектларын гамәлгә ашыру | | районының Музей берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| 9. | «Гасырлар аша хикмәтле акыл» күргәзмә проектын гамәлгә ашыру (Казан шәһәренең җәмәгатьчелек киңлекләрендә Каюм Насыйриның фикерләрен презентацияләү) | 2025 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| **Фәнни, фәнни-популяр һәм нәшрият проектлары** | | | |
| 10. | Каюм Насыйри исемендәге төбәкара яшүсмерләр фәнни-тикшеренү укуларын үткәрү | 2025 елның гыйнвары – апреле | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 11. | Россия Федерациясе субъектларының мәгариф оешмалары педагоглары арасында Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулуга багышланган «Музей һәм мәктәп: үсеп килүче яшь буынны тәрбияләүдә Каюм Насыйри мирасы» төбәкара фәнни-гамәли семинарын үткәрү | 2025 елның марты | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 12. | «Мин игелекле эш эшләдем...» онлайн-платформасында лекцияләр циклын үткәрү: галим һәм мәгърифәтче Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан | 2025 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 13. | Каюм Насыйриның тормыш эшчәнлегенә һәм иҗатына күзәтү ясауга багышланган фәнни-популяр онлайн лекцияләр циклын үткәрү | 2025 ел | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 14. | Казан (Идел буе) федераль университетының Каюм Насыйри институтындагы фәнни-мәгариф үзәкләре тыңлаучылары өчен «Каюм Насыйри – татар тел белеменә нигез салучы» фәнни-популяр лекциясен үткәрү | 2025 ел | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 15. | Каюм Насыйри әсәрләре җыентыгын ике томда (татар телендә) бастырып чыгару | 2025 ел | «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «Татар китап нәшрияты» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе (килешү буенча) |
| **Фильмнар, телевизион һәм радиотапшырулар, репортажлар, мәгълүмат чаралары** | | | |
| 16. | «7 дней» программасында Каюм Насыйрига багышланган махсус репортаж булдыру һәм аны күрсәтү | 2025 ел | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) |
| 17. | Яңа архив материаллары һәм тикшеренүләр нигезендә Каюм Насыйриның тормышы һәм | 2025 елның феврале | «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | иҗаты турында очерк язу | | агентлыгы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 18. | Каюм Насыйри исемендәге премия алуга конкурс оештыру һәм уздыру | 2025 елның мае – августы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 19. | Бу - Бөек татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның ватаны – Кече Шырдан авылының мәдәни яңарышы турында «Место притяжения» документаль фильмын (режиссеры Светлана Серова, 2022 ел) күрсәтүне оештыру | 2025 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 20. | Каюм Насыйриның «Үги кыз», «Байдек», «Өч угыл» әкиятләре буенча балалар өчен нәфис фильм төшерү | 2025 ел | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 21. | Каюм Насыйрига багышланган сюжетлар циклын булдыру һәм «Татарлар», «Здравствуйте», «Манзара» программаларында күрсәтү | 2025 ел | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) |
| 22. | Массакүләм мәгълүмат чараларында «Каюм Насыйри һәм XXI гасыр» темасына басмалар циклын булдыру (иҗади мирас, заманча интерпретацияләр) | 2025 ел | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |

______________________